БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 ноябрь 2018 ел № 144

**2018 елның 9 аена Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. 2018 елның 9 аена Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында мәгълүматны керем буенча еллык план 877538159,08 сум булганда - 648072047,19 сум күләмендә, чыгым буенча еллык план 914505469,16 сум булганда - 653301067,30 сум күләмендә, 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә игътибарга алырга.

2. Балтач муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.С.Галимуллинга Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы белән бергә:

- авыл җирлекләре башлыкларының, Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең, районның бюджет учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт автомашиналары өчен ягулык-майлау материалларының айлык лимитларын билгеләргә;
- 2018 елның 10 аенда районның муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан электр энергиясе һәм табигый газ куллану чыгымнарына анализ үткәрергә;
- районның муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тукланыны оештыру буенча балалар-көннәр санына тулы анализ үткәрергә;
- анализ нәтиҗәләре буенча Балтач муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре белән конструктив киңәшмә үткәрергә

3. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин